| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.01.2025 п.г.т. Алексеевское № 20

**Башкарма комитетның 22.03.2024 ел, № 106 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын төзү һәм аларның эшен оештыру турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының 2024 елның 12 сентябрендәге М-11-3271 номерлы хаты нигезендә һәм Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында

**карар бирәм:**

1. Башкарма комитетның 22.03.2024 № 106 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын төзү һәм аларның эшен оештыру турында» карары тексты буенча тиешле килештә, «Алексеевск муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру пункты» сүзләрен «Алексеевск муниципаль районы территориясендә эвакуацияләнгән, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пункты» сүзләренә алмаштырырга.
2. Халыкны вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктлары башлыкларына эвакуацияләнүче, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән кешене вакытлыча урнаштыру һәм тукландыру пунктларының оештыру-боерык бирү документациясенә үз боерыклары белән үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.
4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**